
Ярты гасыр элек язнын матур мартында Атюрьево районы  Дәлек -Малый Шуструй (Делюково) авылында гомер иткән Шамиль Инятулла улы  һәм Нурия Абдрахман кызы Совешовлар гаиләсендә икенче бала буларак Наилә исемле кызлары туа.
Наилә балачактан ук зирәк, акыллы бала булып vсә. Большешуструй гомуми топ мәктәпне тәмамлагач, Краснослободск  медицина училищесына укырга керә ул. Тырышлыгы кечкенәдән ук кvренгән Наилә Шамиль кызы бу белем йортын “кызыл диплом” белән тәмамлый.Теорияне практикада унышлы кулланып, зур казанышларга ирешә шәфкать туташы. Бер урында тукталып торырга яратмаган кеше белемен тулыландырырга уйлап, бер имтихан гына тапшырып, Н.П.Огарёв исемен йорткән МГУнын медицина факультетына укырга керә.       Укырга яраткан Наилә Шамиль кызы, бар кочен куеп, терапевт белгечлеген vзләштерә. Краснослободск дәваханәсендә интернатура vткәндә, бvгенге тормыш иптәше Сергей белән танышып, бер гаилә сукмагыннан vтәргә вәгъдәләшеп, туй уйныйлар. Элек, вузны тәмамлагач, эш урынын кvрсәтеп направление бирә иделәр. Шулай яшь терапевт Наилә Шәмил кызы Торбеево районы дәваханәсендә хезмәт биографиясен башлап жибәрә. Гаиләсе дә ишләнеп китә: ике бала доньяга тудыра ул. Олкән улы Арнольд бvген банк олкәсендә хезмәт итсә, икенчесе – Альберты, Мәскәv транспорт һәм элемтә институты студенты.
Торбеево һәм Атюрьево кешеләренен һәрберсен терапия бvлеге житәкчесе, баш терапевт Наилә Шамиль кызы Якунина-Совешова дәвалаган, шуна табибнын белемле белгеч икәнлеген барысы да дәлилли. Ул 25 ел элек биргән Гиппократ антына тугрылыклы табиб. Анын оендә дә эшендә кvк; я кинәш сорап, я рәхмәтләрен белдереп еш шалтыраталар. Тырыш хезмәтен бәяләгән торле дәрәҗәдәге Хормәт грамоталары да бар, әмма пациентынын рәхмәте анын очен ин зур бvләк.
Наилә Шамиль кызынын матур гаиләсе, ул бәхетле. Эштән сон зур ойләре тирәсендә чәчәкләрнен торлесен кvп иттереп vстерә. Бакчасында vстергән уныштан кышка тәмлvшкалар әзерли. Ул тагы унган кулинар да; бәлешләрен, пәрәмәчләрен теленне йотарлык тәмле иттереп пешерә. Тагы ул оста жырчы да. Татар жырларын «Шумбрат, Мордовия!» фестивалендә жырлап Торбеево районын мактый.
Наилә Шамиль кызын Алтын  юбилее унаеннан якыннары - Шамиль әтисе, тормыш иптәше Сергей, ике улы, Римма сенелесе һәм кардәшләре Вильдан, Надия гаиләләре белән, Совешовлар династиясе кайнар котлап изге теләкләр юллыйлар.
Сина озын гомер, бәхет-шатлыклар, жан тынычлыгы, саулык-сәламәтлек, эшендә зур

унышларга ирешvенне телибез. Кайгы-хәсрәт белми, һаман шулай кочле рухлы һәм ярдәмчел, изге кvнелле, балаларыннын һәм оныкларыннын игелеген кvреп озак яшәргә насыйп булсын. Рәхмәтләргә һәм рәхәтләргә торенеп яшә.
Якты кvнелле Наиләне без бик яратабыз, ихтирам итәбез.